Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлеге составына кергән Ачы торак пункты

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елның 23 октябреннән № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 N 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Иске Чишмә авыл җирлегенең Иске Чишмә торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1.Түбән Кама муниципаль районының Иске Чишмә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда гражданнарның үзара салымын 1000 сум итеп кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (гидрант сатып алу, урнаштыру);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (асфальт валчык яисә вак таш сатып алу).

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Чишмә авыл җирлеге башлыгы Е.Ю. Ермаков